СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**

**КАРАРЫ**

**« 11 » декабрь 2019 ел** **№ 292**

**Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Арча муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү кагыйдәләре турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы нигезендә Арча муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Арча муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү Кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карарның нигезләмәләре 2020 елдан башлап һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджетлар төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет-финанс мәсьәләләре буенча Арча район Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга..

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г.Нуриев

Арча район Советының
«11» декабрь, 2019 ел, №292
карарына кушымта

**Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Арча муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү**

**КАГЫЙДӘЛӘРЕ**

1. Әлеге Кагыйдәләр гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Арча муниципаль районы бюджетыннан Арча муниципаль районының авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Субвенцияләр җирлекләр бюджетларына гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында бирелә.

3. Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бирү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү чыганагы булып федераль бюджеттан бирелә торган Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетына субвенция тора.

4. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларының баш бүлүчесе булып Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тора.

5. Җирлек бюджетына субвенция күләме «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларыннан авыл җирлекләре бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан исәпләү Методикасы нигезендә билгеләнә.

6. Муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бүлү «Тиешле финанс елына һәм план чорына Арча муниципаль районы бюджеты турында»гы Арча район Советы карары белән раслана.

7. Субвенцияләр җирлекләр бюджетларына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетында

каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм Башкарма комитетка әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

8. Субвенцияләр гражданлык хәле актлары язмаларын төзү һәм башка юридик әһәмиятле гамәлләрне башкару өлешендә түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашыруга бирелә:

хезмәт өчен түләү һәм хезмәткә түләү буенча түләүләр;

командировка чыгымнары;

элемтә хезмәтләре;

транспорт хезмәтләре;

коммуналь хезмәтләр;

мөлкәттән файдалану хезмәтләре;

эш, мөлкәт эчтәлеге буенча хезмәтләре;

башка эшләр, хезмәтләр;

төп милек сатып алу;

матди запаслар сатып алу;

салымнар, җыемнар һәм башка түләүләрне түләү;

башка чыгымнар.

9. Субвенцияләрне тоту җирлекләр бюджетларын үтәүгә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең (алга таба - Казначылык) территориаль органнарының шәхси счетлары аша гамәлгә ашырыла.

10. Башкарма комитет, финанслауның иң чик күләмнәрен җиткерүгә Казначылыктан чыгым расписаниесе алганнан соң җиде эш көне эчендә, Казначылыкка субвенцияләр акчалары исәбеннән җирлекләргә субвенцияләр күчерү өчен касса чыгымнарына гариза бирә.

11. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары, һәр квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча, Башкарма комитетка гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә финанс тәэминаты чыганагы субвенция булган территорияләрдә Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы белән килешү буенча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча җирлекләр бюджетлары чыгымнары турында хисап тапшыралар.

12. Башкарма комитетка тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына йөкләнә.

13. Субвенцияләр бирү шартларын бозган очракта, Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә, әлеге акчалар муниципаль район бюджеты кеременҙә күчерелергә тиеш.

14. Субвенцияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына бирелмәгән субвенцияләрнең калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, муниципаль район бюджеты кеременҙә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субвенцияләр максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

16. Субвенцияләрнең максатчан кулланылышын контрольдә тотуны законнар нигезендә Башкарма комитет һәм муниципаль районның финанс органы башкара.